**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципального района**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

---

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«04» май 2021 ел** **№ 91**

Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 11 декабрендәге 359 номерлы«Азнакай муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган, «Азнакай муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында «Федераль законның 7 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 19 декабрендәге 433-ФЗ номерлы Федераль законны үтәү йөзеннән карар бирә:

1.Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2019 елның 11 декабрендәге 359 номерлы«Азнакай муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карары белән расланган, «Азнакай муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыру» муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 пунктының 3 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

- чит дәүләтнең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемә итү;

Граждан хәле актларын теркәү органнары яисә Россия Федерациясе консуллык учреждениеләре тарафыннан бирелгән уллыкка алу турында таныклыклар;»;

1.2. 3 бүлекнең 3.8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Муниципаль хезмәт түләүсез күрсәтелә торган гражданнар категорияләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартын раслау турында»2015 елның 3 мартындагы 130 номерлы карарында билгеләнә.

2. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга:

http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмати-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru//.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов